ГЛАВА НИЖНЕУСЛОНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ТҮБӘН ОСЛАН
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.11.2015 Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48. с. Нижний Услон 2

«2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге бюджеты турында" Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең бюджет карары проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегендә яшәүчеләрнең хокукларын яклау максатыннан, 2016 елга Түбән Ослан муниципаль районының "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 28 статьясы һәм "Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең 19 нчы Уставы нигезендә гавами тыңлаулар уздыру юлы белән 2016 елга Түбән Ослан авыл җирлеге бюджеты проекты буенча фикер алышуда катнашу өчен,

Карар бирәм:

1. "2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең бюджеты турында" Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең бюджет карары проекты буенча гавами тыңлауларны билгеләү турында

2. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

2.1. Үткәрү датасы һәм вакыты - 2015 елның 1 декабрендә 11.00 сәгатьтә;

2.2. үткәрү срогы - 1 көн;

2.3.үткәрелү урыны - Түбән Ослан авылы, Завод урамы, 55нче йорт Башкарма комитеты бинасында;

2.4. фикер алышына торган мәсьәлә буенча чыгыш ясау хокукы белән халык алдында тыңлауларда катнашу өчен тәкъдимнәр һәм искәрмәләр бирелгән адрес– Түбән Ослан авылы Завод урамы 55 йорт Түбән Ослан авыл җирлеге башкарма комитеты секретаре Чемоданова Л. В. гариза бирергә мөмкин (эш көннәрендә - 8.00 дән 16.00 гә кадәр);

2.5. Чыгыш ясау хокукы белән гавами тыңлауларда катнашуга заявкалар бирү срогы - 2015 елның 1 декабренә кадәр (тел 3-05-44).

3. Югары Ослан муниципаль районының Түбән Ослан авыл җирлеге башкарма комитетына:

3.1. Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге Советының "2016 елга Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге бюджеты турында" гы карары проекты буенча ачык тыңлауларны гамәлдәге законнар һәм әлеге карарда билгеләнгән срокларда әзерләргә һәм үткәрергә;

3.2.гавами тыңлаулар үткәрү йомгаклары буенча Югары Ослан муниципаль районы Советына гавами тыңлаулар беркетмәсе, гавами тыңлаулар нәтиҗәләре буенча бәяләмә, шулай ук Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлегенең 2016 елга эшләнеп беткән (үзгәрешләр кертелгән очракта) проектын тәкъдим итәргә.

4. Әлеге карарны "Югары Ослан муниципаль районы Түбән Ослан авыл җирлеге бюджеты турында" Югары Ослан муниципаль районы Советы карары проектын 2016 елда Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Югары Ослан муниципаль районы
Түбән Ослан авыл җирлеге башлыгы А. З. Шәйдуллин